Зәки Нури

# Саный беләм



тиен

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1962

С (ТАТ.) 2
Н 81

С/тат/2 ~~3602~~
Н81
Нури З.
1962
Саный беләсеңме?
0-11

…ЛАЛАР ӨЧЕН

Санарга өйрәнәм көн дә,
Бер дә тик торып булмый;
Санау өчен тирә-юньдә
Әйбер җиткереп булмый.

БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТ
Инв. № ~~3602~~ 6336



25

1

## БЕР

Кәгазьгә язып карасаң,
Таяк шикелле була.
Нәрсә бер була санасаң?
Сәгать бер телле була,
Туган ил бер була җирдә,
Кояш бер була күктә.
Бик күп берне җыйсаң бергә —
Берләр әйләнә күпкә.




1 1 1 1 1 1

## ИКЕ

Муенны боргалап сузып
Икеле сан шикелле,
Ике аккош килә йөзеп...
Килешләре сөйкемле!
Тукран килеп „тук-тук!“ итте,
Каргалар „Кар-кар!“ диләр.
Һәр кошның канаты ике,
Һәр икене — пар диләр.

2



1+1=2 1+1=2

## ӨЧ



Шар булып тулганга кадәр
Ай урак төсле була.
Ике айны кушып әгәр
Сан язсаң — өчле була.
Санап әйтәм: — „Галстукта
Була икән өч оч“, — дим.
Өч очкыч чөям дә күккә,
Карап торам: „Оч, Оч!“ — дим!




1 + 2 = 3 2 + 1 = 3

## ДҮРТ

Урындык дүртлегә охшый —
Әйләндереп капласаң.
Дүрт булалар — икешәр кеше
Кара каршы атласа.
Бергә берне кушсаң — ике,
Ике икең — дүрт була.
Санадым мин дүрткә тикле,
Дүрттән артса — күп була.





2 + 2 = 4 1 + 3 =

5

## БИШ

Койрык өстә, муен аста...
Ул санны мин биш димен.
Тәрәзәм каршына баскан
Аккаеным биш минем.
Бер каенда биш тармак бар,
Бер шкафта — биш киштә,
Һәр кулымда биш бармак бар,
Абыем укый бишкә.



+3=5 4+1=5

## АЛТЫ

Сызам божра, өстим койрык —
Шулай язам алтыны.
Алты җирдә дөрли куерып
Алты учак ялкыны.
Идел буйлап алты көймә
Йөзеп узды ярышып;
Өч каптырма һәм өч төймә —
Алты була барысы.

6



2+4=6 3+3=

7

## ЖИДЕ

Абыем бер сан сызды да:
„Бу булыр җиде!“ — диде.
Мин санап киттем тиз генә:
Чәшкәбез җиде иде.
Абыйның карандашлары
Җидәү иде тартмада,
Көннәрне саный башладым:
Җиде чыкты атнада!



…+4=7 2+5=7

8

## СИГЕЗ

Аслы-әсле ике бөжра,
Берсе берсенә тигез.
Белмәсәң син, миннән сора —
Шул була инде сигез.
Ялтырап торган чыбыкка
Җиде карлыгач кунды,
Әнә тагын берсе оча —
Сигез карлыгач булды.



4+4=8 3+5=…

9

## ТУГЫЗ

Алтым тугызга охшады —
Алтым баштүбән баскан.
Тугыз машина эшләде
Нигез салганда таштан.
Самолётлар өчәр-өчәр
Очканны карап калдым.
Өчәр-өчәр булды өчәү —
Тугызны санап калдым.



+6=9 4+5=9

## УН

Тутырыйм дисәң унга син,
Карандаш ал да кулга син:
Бер янына нуль өстә —
Шул булыр ун — бер дистә!
Без җәен чебеш карыйбыз!
Чебешләр тиз үсә икән.
Әйдә дистәләп саныйбыз —
Чебешләрем ничә икән?!

10



5+5=10 4+6=1

Унга хәтле саный беләм!..
Күбрәкне белсәм иде, —
Тизрәк үсеп, абый белән
Мәктәпкә йөрсәм иде!

Инв № ~~3602~~
6336



*Заки Нури*

(Нурутдинов Заки Шарафутдинович)

УМЕЮ СЧИТАТЬ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Б. М. Альменов*

Техник редакторы *Ф. Х. Габдуллажанова*

Корректоры *Н. Г. Гобәйдуллина*

Производствога бирелде 13/X-61 ел. Басарга кул куелды 21/XI-62 ел. Кәгазь форматы 70x92 1/16. Учетн.-изд. табак 1,63. Басма табак 1,(1,17). Тираж 20000 экз. Заказ № 1587. Бәясе 11 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1962 ел.